КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 2 апрель г.Казань № 200

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 138 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә үсемлекчелек һәм терлекчелек тармакларын үстерүнең максатчан күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибе.»;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә үсемлекчелек өлкәсендә, орлык бәрәңге, ачык грунт яшелчәләре һәм озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Орлык бәрәңге һәм (яки) озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә булышлык күрсәтүгә бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = P \times S,$$

монда:

W – орлык бәрәңге һәм (яки) озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә булышлык күрсәтүгә бирелә торган субсидия күләме сумнарда;

P – агымдагы финанс елында алучыда булган орлык бәрәңге һәм (яки) озын сүсле җитен утыртылган чәчү мәйданы;

S – орлык бәрәңге һәм (яки) озын сүсле җитен утыртылган 1 гектар мәйданга субсидия ставкасы түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = SR + (SR \times 42/58),$$

Монда SR – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән билгеләнә торган субсидия ставкасы.

авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә орлык бәрәңге һәм (яки) озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә булышлык күрсәтүгә бирелә торган субсидия күләме гамәлдә тотылган чыгымнар күләменнән артык була алмый.»;

әлеге карарга Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә үсемлекчелек һәм терлекчелек тармакларын үстерүнең максатчан күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен өстәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин